ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 34-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 34-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәмmәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 23 декабре
№ 143-VII ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында**

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенә (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә), (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 76 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлектәге 17 пунктны өстәп, үзгәреш кертергә:

«17) 2024 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәрге чорда файдалануга тапшырылган, кунакханәләрне классификацияләү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган нигезләмә буенча бирелгән «өч йолдыз»дан да ким булмаган категорияле, 50 номердан күбрәк номер фонды булган кунакханәләрдә вакытлыча яшәү өчен урыннар бирү буенча хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән мөлкәткә карата.

Салым ташламасы күрсәтелгән мөлкәт объекты файдалануга тапшырылган айдан соң килә торган айның 1 числосыннан башлап, аны аерым исәпкә алу алып барылган очракта, 10 ел срокка бирелә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының**
**3 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектына**
**АҢЛАТМА**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проекты «өч йолдыз»дан да ким булмаган категорияле кунакханәләрдә вакытлыча яшәү өчен урыннар бирү буенча хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән мөлкәткә карата оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү максатларында эшләнгән.

Салым ташламасы 2024 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәрге чорда файдалануга тапшырылган, «Россия Федерациясендә туристлык эшчәнлеге нигезләре турында» 1996 елның 24 ноябрендәге 132-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кунакханәләрне классификацияләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 18 ноябрендәге 1860 номерлы карары нигезендә «өч йолдыз» һәм аннан да зуррак категория бирелгән һәм 50 номердан башлап тагын да күбрәк номер фонды булган кунакханәләргә кагыла.

Закон проекты салым ташламасын күрсәтелгән мөлкәт объекты файдалануга тапшырылган айдан соң килә торган айның 1 числосыннан, аны аерым исәпкә алу алып барылган очракта, 10 ел срокка бирүне күздә тота.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

# ИСЕМЛЕГЕ

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының**
**3 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.

2024 елда төзелгән объектлар буенча бирелгән салым ташламалары күләме елына 200 млн сум дәрәҗәсендә бәяләнә.